**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АКСУБАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**ЯҢА ИБРАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**15.06.2015 ел** **№ 17**

Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Өченче чакырылыш Советы депутатларын сайлау турында

"Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында" Федераль законның 10 статьясындагы 3, 7 пунктларына, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 6 статьясындагы 2 өлешенә, 105 статьясындагы 1 өлешенә, «Яңа Ибрай авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясына ярашлы рәвештә, Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы карары:

1. Өченче чакырылыш Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауны 2015 елның 13 сентябренә билгеләргә.
2. Әлеге карарны кабул ителгәннән соң биш көннән дә соңга калмыйча «Сельская Новь» район газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районының рәсми сайтында "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга. http://Aksubayevo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүне Татарстан Республикасы Аксубай муниципаль районы Яңа Ибрай авыл җирлеге Советы Рәисе Кәбиров Фәхим Хәмәт улына йөкләргә.

Яңа Ибрай авыл җирлеге
Советы Рәисе: Ф. Х. Кәбиров